КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 11 сентябрь № 663

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым дәүләт гомуми белеме бирү оешмалары исемнәрен үзгәртү турында» 2015 ел, 14 март, 153 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым дәүләт гомуми белеме бирү оешмалары исемнәрен үзгәртү турында» 2015 ел, 14 март, 153 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар, тәрбияләнүчеләр өчен «86 нчы «Өмет» махсус (коррекцияле) VI төр гомуми белем бирү интернат мәктәбе» дәүләт бюджет махсус (коррекцияле) белем бирү учреждениесе исемен «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 86 нчы «Өмет» интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе дип;»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар, тәрбияләнүчеләр өчен «Яр Чаллы шәһәренең махсус (коррекцияле) V төр башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» дәүләт бюджет махсус (коррекцияле) белем бирү учреждениесе исемен «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 89 нчы башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе дип;

утыз алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Минзәлә махсус (коррекцияле) VIII төр гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет махсус (коррекцияле) белем бирү учреждениесе исемен «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен Минзәлә интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе дип;

пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар, тәрбияләнүчеләр өчен «Зеленодольск шәһәренең 2 нче махсус (коррекцияле) VIII төр гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет махсус (коррекцияле) белем бирү учреждениесе исемен «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Зеленодольск шәһәренең 2 нче мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе дип».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\663.doc